**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КРУГЛОЕ ПОЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«17» март 2021 ел № 8/1

**«Круглое Поле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 22 август 27/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

РФ Салым кодексының 394 статьясы 1 пункты 1 пунктчасы, 5 статьясы 4 пункты, «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Круглое Поле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Круглое Поле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 22 август 27/2 номерлы карарына (2020 елның 28 февралендәге 61/1 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яки яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3% күләмендә җир салымы ставкасын билгеләү турында 2 пунктның 8 пунктчасы 2018 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

2. «Круглое Поле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 22 августа 27/2 номерлы карарының 5 пунктын төшереп калдырырга.

3. Әлеге карар мәгълүмат стендларында, хокукый мәгълүмат порталында һәм районның рәсми сайтында урнаштырылып, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән бер айдан соң үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Э.Р. Низамиева